# Искергән сүзләр.

*Зур бәхетләр*
*сызганып эшкә бирелгәннән килә,*
*Аһ! Оят,хурлык,*
*түбәнлекләр иренгәннән килә.*
*Булса калдырмак берәү*
*ушбу җиһанда изге ат,*
*Тир белән тапсын ашарын,*
*итсен, әлбәт, иҗтиһад.*
*Һәр олугълар*
*эшләгәнлектән олугълыклар таба,*
*"Уйнады" дип бирмиләр*
*ушбу җиһанда мәртәбә.*
Г.Тукай.(1911)



- җиһан
- иҗтиһад
- ушбу
- олугъ
- мөкаддәс

| 1нче төркем | 2нче төркем | 3 нче төркем | 4 нче төркем |
|---|---|---|---|
| өяз<br>сөңге | мәхәллә<br>ядрә | инсан<br>аршын | арык<br>вә |

# Искергән сүзләр

- өяз
- мәхәллә
- сөңге
- ядрә
- аршын
- инсан
- арык
- вә

- Мәгънәләре буенча 1нче баганадагы сүзләр- вакыт узу белән кулланылыштан төшеп калган предмет яки күренеш исемнәре. Аларны *тарихи сүзләр* дип атыйлар. Аларны бары тик тарихи хезмәтләрдә яки шул чор матур әдәбияты әсәрләрендә кулланалар.

- Ә икенче баганадагы сүзләр – хәзерге көндә дә булган предметларның, күренешләрнең искергән атамалары. Аларны *архаизмнар* дип атыйлар.

# Ишәк илә сандугач.

*Ишәк сандугачны күрде дә, аның янына килеп: "Тыңла әле, дустым! Миңа сине, ул сайрарга бик маһир, дип мактадылар. Менә мин үз колагым илә синең тавышыңны ишетмәкче вә яхшы-начарлыгына үзем хөкем итмәкче булдым", - диде.*

*Сандугач, дәрхаль үзенең һөнәрен күрсәтергә башлап,әллә тагы мең төрле көйләргә борып сайрарга кереште.*

*Ул,бер чут-чут итеп куеп, бер сызгыра, бер назиканә генә тавышын әкренләтеп, бер бөтен урманга вак кына ядрә сибелгән кеби яңгыратып җибәреп, ничек тә булса матуррак сайрарга тырыша иде.*

*(Г.Тукай)*

## Имтияз алган бала.

Тырышты бу бала, чын ләззәт алды инде тәхсилдән;

Югары булды урны “афәрин”нән һәм дә “тәхсин”нән.

Ни кушсаң да укый алды, ни әйтсәң шуны язалды;

Балаларның арасында үзенә “имтияз” алды.

Беренче кәррә мөмтаз булса бер инсан туганнан соң,

Фәхерле имтиязларны алыр үскәч тә аннан соң.

"И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә-эш,

Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,

Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел"

Г.Тукай